**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**С О В Е Т**
**Нижнекамского муниципального района**

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Түбән Кама муниципаль районы**
**С О В Е Т Ы**

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**№ 33** **11 апрель 2018 ел**

**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Түбән Уратма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 маддәсе, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставы нигезендә, күчемсез милеккә ия булучылар һәм күчемсез милек объектлары булдыру,аннан файдалану хокукы алырга теләүчеләр өчен, Түбән Кама муниципаль районы Советы


**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбән Уратма авыл җирлеге Советының 2013 елның 5нче мартында кабул ителгән 4нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Уратма авыл җирлеге биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренең график өлешенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә: Ж-2 “Бакчачылык һәм дача участоклары зонасы”н Ж-1 "Шәхси торак йортлар төзү зонасы" дип үзгәртергә (кушымта).
2. Әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарны Россия Федерациясе территориаль планлаштыру Федераль дәүләт мәгълүмат системасында (ФГИС ТП РФ) урнаштырырга.
4. Гамәлдәге карар үтәлешен контрольгә алуны төзелеш, җир төзү, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы А.Р. Метшин

Кушымта
Түбән Кама муниципаль районы Советының
2018 ел, 11апрель,  33нче карарына

до внесения изменений




после внесения изменений




Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Э.Р. Долотказина